ЯҢА ШӘҺӘР

Югары Ослан районында маркетплейс сатучыларын бер урынга тупларга җыеналар

> 2

ҖЫРЛЫ ЯЗМЫШ

Бөек җырчы Эмиль Җәләлетдиновны соңгы юлга озаттылар

> 3

ЗАПАС АЭРОДРОМНАН

Камил Абдулвахобов – инженер белеме алган укытучы

> 3

КАЛӘМ ХАКЫ

Хезмәттәшебез оештырган бәйгедә укучылар һәм аларның остазларын зурладылар

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 39 (29006) | Сишәмбе | 21 март | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ӘЙЛӘНӘ ДӘ КИЛӘ... КУНАКЛАР

Урамда – яз һәм туристлар. Баксаң, Татарстанда экскурсия хезмәтенә бәя бер ел эчендә (2022 елның гыйнварыннан 2023 елның гыйнварына) 32 процентка арткан икән. Туристларны күпләп кабул иткән Татарстан һәм аның башкаласында эшләүче экскурсоводлар нинди хакка эшли? Алар нәрсәгә борчыла, нәрсәгә өметләнә? Шул сорауларга җавап эзләдек. Комачау итмәс дип, аяклы энциклопедияләрдән язгы ял чорына киңәшләр дә сорадык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

VIP-тамада, театр белгече, экскурсовод-гид, Казан шәһәре буенча махсус маршрутлар уйлап тапкан Айдар Садыйков – эшенең чын фанаты. Экскурсовод булып нәкъ шундый кешеләр генә эшли ала дигән фикердә ул. Шуңа күрә андыйлар кесә янчыгына бик карамый.

– Бәяләр ул кадәр югары түгел. 5 ел элек сәгатенә 600–700 сум булса, хәзер исә, туристик фирма аша эшләсәң, 700–800 сум түлиләр. Без хәзер үзмәшгуль буларак эшлибез. Керемнең бер өлеше – 6 проценты – дәүләткә китә, – дип сөйләде танылган экскурсовод. – Зөя, Болгар ише җирләргә барсаң, экскурсия вакыты унар сәгатькә сузылса, ярый әле ул. Ә Казанда бит уртача 2–3 сәгатьлек экскурсияләр уза. Керемне үзегез санагыз инде. Экскурсовод эше – сезонлы хезмәт ул. Яңа ел ялларында кеше күп килә, февраль, март айларында экскурсияләр әллә ни юк, май ялларында эшләп алабыз.

Айдар Садыйков әйтүенчә, экскурсовод һөнәренә өстәмә акча эшләү өчен килүчеләр бар. «Уртача яшебез – 60тан өлкәнрәкләр. Экскурсоводлар – тарих белән җенләнгән кешеләр. Аны хобби буларак кабул итсәң генә», – ди. Моңа өстәп, экскурсоводка таләпләр дә бик зур. Рәсми аттестация узу, һәрдаим әзерләнеп тору, имтиханнар, дисеңме. Кешеләр белән элемтә кору да җиңелләрдән түгел.

– Бездән таләп итү күбрәк, ярдәм итү азрак. Теләктәшлек тә кирәкми, тынычлап эшләргә генә комачау итмәгез. Безгә бит эшне табып бирмиләр, без аны үзебез эзлибез. Коронавирус чоры булды. Берәр кеше безнең хәлне белдеме соң? Кыскасы, җиңел эш түгел. Без хәтта автобус шоферына да бәйле. Соңга калырга ярамый, кешеләрне бөтен җиргә вакытында алып килеп җиткерергә кирәк, тиз дә, акрын да сөйләргә ярамый һәм башкалар, һәм башкалар. Экскурсоводлар – туристик индустриянең иң якланмаган өлешедер ул. Без – шәфкать туташы да, бәдрәф, кафе күрсәтүче дә, укытучы да, – ди Айдар Садыйков.

Татарстандагы туризм өлкәсен тагын да чәчәк аттыру өчен тәкъдимнәре дә бар. Шәһәрдә «Шәрык базары» кирәк. «Бөек Ефәк юлы кебек данлыклы, шаугөр килеп торган ярминкә булырга тиеш. Тегендә ефәк халат сатып торсыннар, монда уен коралында көй уйнасыннар! Кешеләргә ул кызыклы булыр иде. Туристлар да үзәк базарыгыз бармы дип еш сорый», – ди Айдар Садыйков. Моннан тыш тугланы популярлаштыру кирәк дип саный ул. Зилант хакында риваять сөйләгәндә төртеп күрсәтерлек нәрсә булса, начар булмас бит. Башкалада һәр районның атамасын күренерлек итеп эшләтү дә ярар иде. «Театрлар җәй айларында эшләми, кызганыч. Туристларга спектакль күрсәтеп, татар телен ишеттереп булмый, – дигән үкенече дә бар әңгәмәдәшнең. – Ярый әле Салават бар. Ул ике атна концерт куя».

– Рәисебез Рөстәм Миңнехановка, җитәкчеләребезгә, Туризм комитетына рәхмәт. Татарстанны, Казанны туристик яктан кызыктыру өчен бик күп эш башкарыла. Без моны күрәбез, санлыйбыз. Кешеләрнең Татарстанга һәм Казанга кабат-кабат әйләнеп кайтасы килә, бу безгә дә файдага, – диде Айдар Садыйков.

Казан Экскурсоводлар гильдиясе әгъзасы Раушания Миңнуллина күбрәк шәхси төркемнәр белән эшли. Бер кеше килсә дә, 50 кеше килсә дә, сәгатенә бертөрле бәя ала ул.

– Туристик фирмалардан экскурсия алган кешеләргә барысы да каралган тулы «пакет» тәкъдим ителә. Алар шул бәягә истәлекле урыннар да карый, ашый-эчә. Мин исә экскурсия генә оештырам да, соңыннан кая барырга, нишләргә дип сораучыларга үз киңәшләремне бирәм, – ди ул.

•2022 елда Татарстан башкаласына 3,6 миллион турист килгән. Бу 2021 елгы саннан 20 процентка күбрәк. Кунакханәләрнең уртача тулылыгы – 65 процент, ә бәйрәм көннәрендә 95 процентка кадәр җиткән.
•«Авито» сайтына кереп, Казан буенча экскурсовод бәяләрен барлап чыктык. Иң арзаны – 500 сум. Шулай ук фотоэкскурсовод дигән хезмәт тә бар. Анысы 5 мең сумнан башлана.

Ахыры 4 нче биттә >

Укытучыны борчымагыз!

Укытучыларның хезмәт шартларын яхшыртырга һәм кирәкмәгән хисапларга бәйле кәгазь эшен киметергә кирәк. Россия Премьер-министры Михаил Мишустин белдергәнчә, вуз укытучыларына да кагыла бу.

Премьер-министр сүзләренә караганда, моның өчен укытучыларның фикерен белешергә кирәк. «Искиткеч дәрәҗәдә белемле укытучылар кирәкмәгән, аңлаешсыз хисаплар тапшыру зарурилыгы турында күп сөйли. Бик күп вакытны ала бу. Алар аны укучылары белән уздыра алыр иде», – дип билгеләп үткән Хөкүмәт башлыгы. Ул Рособрнадзор җитәкчесе Анзор Музаевка әлеге хәлне ачыклап бетерергә кушкан.

Премьер-министр әйтүенчә, мәктәп укытучылары һәм студентларның иң югары стандартлар буенча сыйфатлы белем алуы кирәк. Илнең икътисадый һәм технологик мөстәкыйльлеге шуңа бәйле.

Эшлиләр һәм эшләтәләр

Татарстанда кече һәм урта эшмәкәрлек оешмалары саны 168 меңнән артып киткән (узган елдагыга караганда 1,6 процентка күбрәк). Бизнесны алып бару шартларының яхшыруы турында сөйли бу. Шул исәптән «Кече һәм урта эшмәкәрлек» илкүләм проектын тормышка ашыру нәтиҗәсе дә. Аның максаты – бизнеска, эш башлаудан алып, товарын экспортка чыгаруга кадәр барлык этапларында ярдәм итү.

Узган елда республикада кече һәм урта эшмәкәрлек оешмаларында эшләүчеләр саны 800 меңгә якынлашкан. Бу – Татарстанда булдырылган эш урыннарының 40 проценты чамасы. 2023 ел ахырына кече һәм урта эшмәкәрлек оешмаларында эшләүчеләр, үзмәшгульләр 810 мең кешегә җитәр дип фаразлана.

Авылдан күчтәнәч

Казанда язның беренче ярминкәсендә барлыгы 54 миллион сумлык товар сатылган. Шәһәрнең Кулланучылар базары комитеты рәисе Руслан Фазылҗанов әйтүенчә, шимбә ярминкәләрендә кибеттәгедән арзанрак бәядән фермер продукциясе юнәтергә мөмкин. Аларда яшелчә, ит, хуҗалык өчен кирәк-ярак сатыла.

Ярминкәләр Казанда 15 урында үткәрелә. Казанда яшәүчеләр ярминкә уздыру урыны, эш сәгатьләре, товарлар ассортименты турында «кайнар линия» телефоны ((843)223-27-82) аша белешә ала. Башкалабызда авыл хуҗалыгы ярминкәләре 22 апрельгә кадәр һәр шимбә саен үткәреләчәк.

Авыручылар кимегән

Узган тәүлектә Татарстанда коронавирус йоктыруның 191 очрагы теркәлгән. «Стопкоронавирус.рф» хәбәр иткәнчә, биш кеше хастаханәгә озатылган. Портал мәгълүматларына караганда, хастаханәгә озатылучылар саны рәттән өч көн кими (28, 20 һәм 5).

Пандемия башланганнан бирле республикада барлыгы 201879 кеше коронавирус йоктырган. Шуның 198616сы сәламәтләнгән, 2010 сырхау вафат булган (соңгы тәүлектә бу күрсәткеч үзгәрмәгән).

Яңалык

Үзе дәвалап, үзе юатсын

Терапевт, педиатрлар бер үк вакытта психиатр да булырга тиеш. Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы шундый тәкъдим белән чыккан. Халык иң беренчеләрдән булып ярдәм сорап килгән әлеге табибларга яңа белгечлек үзләштерергә туры киләчәк. Шул рәвешле илдәге психиатрлар санын арттырмакчылар.

pixabay.com

Рәсми саннардан аңлашылганча, бүген Россиядә психиатр, психотерапевтлар белән тәэмин ителеш 82 процент тәшкил итә. Әлеге белгечләрнең санын гамәлдәге табиблар хисабына арттырмакчылар. Аларны укыту программасы да эшләнгән инде. Ул биш айга исәпләнгән. Шушы махсус курсларны узганнан соң гомуми практика табиблары, педиатрлар кешегә тиз арада психологик ярдәм күрсәтә, психик тайпылышлары булган кешеләргә дөрес диагноз куеп, аларны дөрес итеп дәвалый да алачак.

Әлеге проект ярдәмендә илдәге психотерапевтлар санын да арттырмакчылар. Әмма бу белгечлекне «Психиатрия-наркология», «Психиатрия», «Сексология», «Суд-психиатрия тикшерүе» юнәлеше буенча эшләүче табиблар гына үзләштерә алачак. Аларга дүрт ай чамасы укырга туры киләчәк.

«Һәр ике программада да практик биремнәргә зур урын бирелгән. Табиблар, теоретик белемнәр генә алып калмыйча, өйрәнгәннәрен гамәлдә дә сынап карый алачак. Психик тайпылышлары булган конкрет кешегә ярдәм күрсәтергә дә, белемнәрне махсус уеннарда кулланып карарга да мөмкин булачак», – диелә министрлык хәбәрендә.

Гомуми практика табибы Гөлназ Котдусова бу яңалыкка уңай карый. Ник дигәндә, аларга ярдәм сорап мөрәҗәгать итүчеләр арасында психиатр ярдәменә мохтаҗ булганнар еш очрый икән.

– Аларга күңел кушканча, үземнең эчке сиземләвемнән чыгып ярдәм итәргә, киңәш белән булса да хәлен җиңеләйтергә тырышам. Махсус белемем булса, андый чакларда җиңелрәк булыр иде. Аннары бу яңалык тик торганнан гына кертелгәндер дип уйламыйм. Махсус хәрби операциядән соң психиатр, психотерапевтларга эш бермә-бер артачак бит, – ди табиб.

Дөрестән дә, соңгы арада медицина тармагының бу юнәлешенә игътибар сизелерлек артты. Әле күптән түгел генә Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы каршында авыр яраланганнан соң стресска бирешү аркасында тайпылышлары булган кешеләргә махсус психологик ярдәм күрсәтүче эшче төркем булдырылды. Узган ел азагында Россия Президенты Владимир Путин да психологик ярдәм күрсәтү мәсьәләсенә игътибарны арттырырга кушкан иде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

deti.gov.ru

Мария ЛЬВОВА-БЕЛОВА, Россия Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил:

Чит илдә туган баланың әтисе яки әнисе Россия гражданины булса, балага да шундый ук хокук бирелергә тиеш. Ул үзебезнеке булып калсын, тамырларын белсен. Тели икән, теләсә кайсы вакытта бернинди каршылыксыз кайта алырлык булсын. Балаларыбыз язмышын күзәтеп барыйк.

(«Российская газета»дан)

ТАТАРСТАНДА – ЯЗГЫ КЫР ЭШЛӘРЕНӘ ӘЗЕРЛЕК



Тракторлар	95%
Чәчү һәм эшкәртү техникасы	98%
Бөртекле, кузаклы һәм ярма культуралары орлыклары	126%
Шикәр чөгендере орлыгы	95%
Көнбагыш	85%
Кукуруз	93%
Ашлама	60 кг/га

Җылы килә

Татарстанга яңгырлы һәм бик җылы һава килә. Көндез +11 градуска кадәр җылытачак. Уртача температура нормадан 6–8 градуска югарырак булачак.

Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, чәршәмбе – 22 мартта көндез +4…+9 градус. Төнлә дә җылы: 0…+3. Көндез явым-төшем көтелми. Төнлә урыны белән карлы яңгыр булачак. Пәнҗешәмбе – 23 мартта явым-төшем туктаячак. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +6…+11, төнлә 0…–3 градус күрсәтәчәк.

Башлангыч фаразларга караганда, җомгадан якшәмбегә кадәр – 24–26 мартта бик җылы һава торышы сакланып калачак. Көндез җылылык +6…+11 градус чикләрендә тирбәләчәк. Урыны белән яңгыр көтелә.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ЧЫЛБЫР РЕАКЦИЯСЕ БАШЛАНАМЫ?

Көнбатышның Үзәк банклары никадәр генә тырышмасыннар, үткән атнада банк тотрыксызлыгы сериясен туктата алмадылар. Дөрес, өч Америка банкыннан башка кредит оешмалары ябылмады, әмма банк активлары чүплеккә очты. Спекулянтларның югалтулары чамасыз. Сәясәтчеләр һәм финанс базары аналитиклары, хәл 2008 елгы кебек куркыныч түгел, дип расларга никадәр генә азапланса да, 2008 елгы глобаль кризиска караганда дәһшәтлерәк тотрыксызлык күренеш килә. Рәсми даирәләр үз авызлары белән моны танысалар, Жир шарын тиңе булмаган паника биләп алачак һәм эшләр бик начараячак. Вазгыять шулай катлауланмасын өчен, «бишек жыры» жырларга һәм күп итеп акча басарга туры килә. Болай эшләгәндә, егылу акрын булачак, дигән өмет бар. Бәлки, вакытлыча тотрыкланган тукта та торыр, дигән юану да яши. Үткән атнада банклар тирәсендә вакыйгалар бик кызу әйләнде. Америка очкыны Европага килеп төште һәм Швейцариянең зурлыгы ягыннан икенче банкы Credit Suisseның эшләре начараеды. Без йомшаграк итеп әйтергә тырышабыз инде, ә чынлыкта, баш әйләндергеч тизлектә җимерелү барды. Швейцария банклары дөньяда иң ышанычлысы булып санала һәм тотрыклылык символы булып исәпләнә, дөньяның иң атаклы байлары, спекулянтлары һәм караклары үз акчаларын шунда саклаганнар, шуларның акцияләрен сатып алырга тырыша иде. Credit Suisse акцияләре акчаларын шундый итеп җилгәрде: барысы да агач түмәреннән ясалган Буратино хәлендә калдылар. Согуд Гарәбстанының Үзәк банкы аның акцияләрен 3,82 франк бәясеннән сатып алган, хәзер бер акция өчен 0,25 франкка гына өмет итә ала. Калькулятор югалтуның 15,28 тапкыр икәнен күрсәтә. Гарәпләр акцияләргә 1,5 миллиард доллар акча тыккан булганнар, хәзер «инвестиция»ләре 100 миллион долларлардан азрак калган. Банкның 17 миллиард долларлык бондлары бөтенләй нульгә әйләнгән.

Швейцариядә хәтта ял көннәрендә дә ауган банк мәшәкатьләре белән баш ваттылар. Рәсми даирәләрнең бер өлеше, анда Якын Көнчыгыш һәм Азия илләре бай гражданнарының акча саклавын, акционерлык капиталының гарәпләр һәм америкалылар кулында булуын әйтеп, Credit Suisseны коткармаска да өндәде. Ярдәм сорап, Согудиягә мөрәҗәгать итү файда бирмәде, гарәпләр тагын бер тапкыр акчаларын суга салудан баш тарттылар. Бу юллар язылганда, авторга шул мәгълүм булды: Credit Suisseны UBS – Швейцариянең иң эре финанс холдингы 3 миллиард франкка сатып ала. Бер акциягә 0,76 франк бирә. Җомга сәүдәсе ябылганда, банкның акцияләре 1,86 франкка кадәр очсызланган иде, UBS бәяне тагын 2,44 тапкыр төшерә. Мондый алыш-биреш тотрыклылыкка китерерме, анысын якын киләчәктә күребез, Аллаһ теләсә. Бүген АКШның үзендә генә дә 180нән артык банк аварга тора. ФРС үткән атнада, аларны саклау өчен, 300 миллиард доллар акча басты, диделәр. Бу темплар белән доллар әләшү – дозадан үлеп барючы наркоманга яңа доза кадау кебек нәрсә ул, әмма американнарның башка чарасы юк.

Дөньякүләм вакыйгалар ташкыны кайнады үткән атнада, әмма банк тотрыксызлыгы аларның алдыннан бара.

Россиядә

«ГАЗПРОМ»ГА АШЫГЫЧ ЯРДӘМ

Көнбатыштагы зур тотрыксызлык фонында Россиянең хәле ярыйсы кебек. Европадан кендек өзелгәннән соң, инде югалтасы югалды дип, тыныч кына яши алабыз шикелле. Кебек, тоела, шикелле дип еш кулланырга туры килә, чөнки алдавыч чынбарлыкта яшибез. Финанс министры Антон Силуанов, мартта керемнәр артыр, чыгымнар кимер, бюджет дефициты кечерәер, дигән өмет белдерә. Чыгымнарны 15 процентка киметергә туры килгән икән, керемнәр исә бизнестан өстәмә акча җыю хисабына өстәлер, могаен. Бездә бит эшләр хәзер җайланды: Европа алмаган дизель ягулыгын Согуд Гарәбстанына сатабыз. Гарәпләргә кирәге юк аның, үзләре нефть державасы бит. Бездән арзанга алалар да әлекке клиентларыбызга бәя өстәп саталар. Үткән атнада «кара алтын»га бәя төште. Brent бәясе 72 долларга калды, Россиянең «юралс» маркалы нефте 40 доллардан аз гына югарырак. Банклар калтыравы тәгәлләнмәсә, очсызлану дәвам итәр.

Бу юллар Кытай лидеры Си Цзиньпин Мәскәүгә килеп төшәр алдыннан языла. Кытайлар белән стратегик хезмәттәшлек күпме дивиденд бирер – алдан әйтеп булмый. Си – альтруист түгел, үз файдасына йөри, монысына шикләнмибез. Әмма аның Россия чималын алуы, үз технологик товарларын безгә сатуы бүген бик кирәк. Трампның элекке администрациясендә милли куркынычсызлык буенча киңәшче булган Джон Болтон: «Кытайга Россияне үзенең сателлитына әйләндерү файдалы», – дип әйтсә әйтер, Мәскәү өчен Кытайдан башка киң хезмәттәшлек итәрдәй башка дәүләт юк. Аларның финанс системасы әлегә тотрыклы, компартия банкларны кытырышы биялайлар белән тотып торырга тырыша. Россия исә үз сәүдәсен юаньнарга күчереп бетерде диярлек. Пекинның да финанс хәле бик авыр, гадәттән тыш зур әҗәтләр йөгеннән сыгылып килергә генә тора. Коммунистлар шуңа күрә АКШ һәм Европа белән мөнәсәбәтләрне саклаган хәлдә Россия базарын үз кулларына алырга телиләр. Мәскәүгә дә Кытай күчерендә әйләнү әчке базарны тотрыклы итеп тотарга булыша.

Бер тармакта гына Көк асты иле Европаны тулысынча алыштыра алмый. Көнбатыш базарын югалткан «Газпром» бер елга 40 миллиард долларлык акчадан колак кага. Дәүләт Думасында бу югалтуны газны эчке базарда кулллануны арттырып капларга чакырдылар. Сүз күләмне арттыру турында гына түгел, зәңгәр ягулыкка бәяне дә базардан куйдырту турында бара. Газ куллану күләмен дурт тапкыр арттыру яисә бәяне дүрт тапкыр күтәру талап ителә икән. Белгечләр шулай исәпләгән. Бәя күтәрсән, җан башына бер елга өстәмә 22,6 мең сум акча түләргә туры киләчәк. Куллануны арттыру өчен зур мәйданнар бар. Бәя дә бераз күтәрелми калмас, әмма сүз – нигездә сәнәгать куллануны өчен хак арттыру турында. Гади халык кесәсе аның кадәр бәяне күтәрә алмас. Әлегә рәсми карар түгел, Думада «түгәрәк өстәл»дә яңгыраган фикер генә бу.

Рәсми Татарстан

ЯРДӘМ БЕРЛӘШТЕРДЕ



Нәүрүз – кешелеклелек, түземлек, бердәмлек һәм теләктәшлек бәйрәме. «Быел Татарстан Төркиягә әлеге бәйрәмне гәүдәләндергән хисләрне тою мөмкинлеге бирде», – диелә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка Төркия тышкы эшләр министры Мәүлүт Чавушоглудан килгән котлауда.

«Быел Нәүрүзне, 6 февральдә Кахраманмарашта булган ике җир тетрәүнең яраларын төзәтүне дәвам итеп, сагышлы-моңлы хисләр белән каршылыйбыз. Мин шулай ук җир тетрәү фаҗигасеннән соң безгә Нәүрүзне гәүдәләндерүче бердәмлек, туганлык һәм теләктәшлек хисләрен тирәнтен тою мөмкинлеге биргәнегез өчен рәхмәт сүзләрен җиткерәсем килә», – дип билгеләп үткән Чавушоглу.

Министр Россия һәм Төркиягә, шулай ук бөтен дөньяга тынычлык, татулык, үсеш, ә Рөстәм Миңнехановка, Татарстан халкына нык сәламәтлек, бәхет һәм иминлек теләгән.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Төркия Республикасының Казандагы генераль консулы Исмәт Әрикан белән очрашты. Хөкүмәт йортында узган очрашуда ике арадагы хезмәттәшлекне ныгыту, эшлекле элемтәләрне үстерү турында сөйләштеләр.

2023 елның февралендә куркыныч җир тетрәүдән зур зыян күргән Төркиягә ярдәм һәм теләктәшлек күрсәткән өчен, Исмәт Әрикан Татарстан халкына рәхмәт әйтте. Татарстанның зур сәнәгать предприятиеләре, хәйрия фондлары, дини оешмалар, шулай ук республика яшәүче меңләгән кеше акча җыйды һәм гуманитар ярдәм юллады. «Без сезнең йөрәкләрегезнең безнең белән булуын сиздек», – диде генераль консул.

«Безнең бурыч – бу авыр вакытта тугандаш төрек халкына ярдәм итү, без читтә кала алмадык», – диде Рөстәм Миңнеханов. Татарстан Рәисе әйтүенчә, Төркиядәге фаҗига бөтен дөньяны тетрәндерде, ә ярдәм итү теләге кешеләрне берләштерде.

Африка белән дуслык ныгый

Дәүләт Советы Рәисе, Россия Закон чыгаручылар советының Халыкара хезмәттәшлек проблемалары буенча комиссиясе рәисе, Азия һәм Африка халыклары белән хезмәттәшлек һәм теләктәшлек комитетының попечительләр советы әгъзасы Фәрит Мөхәммәтшин «Россия – Африка күпполярлы дөньяда» Икенче халыкара парламент конференциясе утырышында катнашты. Чара Мәскәүдә узды.

Конференцияне Дәүләт Думасы оештырган. Анда Африканың күпчелек илләреннән 40тан артык рәсми делегация, Россия һәм Африка илләренең фән-мәгариф өлкәсе вәкилләре, белгечләр, Россия сенаторлары, Дума депутатлары катнаша. Конференция дә күпполярлы мөнәсәбәтләр барлыкка килү шартларында Африка илләре белән парламентара хезмәттәшлекне ныгыту, икътисадта, фән һәм мәгариф өлкәләрендә хокукый мөнәсәбәтләрне үстерү мәсьәләләре карала.

Конференциядә катнашучыларга Россия Президенты Владимир Путин мөрәҗәгать итте. «Россиянең Африка белән хезмәттәшлеге яңа биеклеккә чыгып килә, – дип ассызыклады Владимир Путин. – Безнең ил Африка дәүләтләре белән узара мөнәсәбәтләргә зур әһәмият бирә һәм алга таба да шулай булачак. Бу – Россия тышкы сәясәтендә өстенлекле юнәлешләрнең берсе, дип әйтү һич тә күпертү булмаячак».

Президент билгеләп үткәнчә, Африка дәүләтләре дөнья эшләрендә тоткан урыннарын даими ныгытып, икътисад һәм сәясәттә үзләре турында торган саен ышанычлырак белдереп килә. Һичшиксез, Африка күпполярлы дөньяда лидерларның берсенә әйләнәчәк. Моның өчен барлык алшартлар бар, дигән фикердә Владимир Путин.

Фәрит Мөхәммәтшин «Россия – Африка» конференциясе кысасында Африка илләре делегацияләре җитәкчеләре белән очрашулар уздырды. Ул, форсаттан файдаланып, Африка дәүләтләре вәкилләрен быел май аенда Казанда узачак «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum-2023» Халыкара икътисад форумында катнашырга чакырды.

МӨМКИНЛЕК ҺӘМ ИНВЕСТИЦИЯ КИСЕШКӘНДӘ

Буада күпләп балык үрчетә башлаячаклар, ә Югары Осланда быел ук өр-яңа шәһәргә нигез салыначак. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендә узган Инвестиция советы утырышында сигез проект тәкъдим ителде һәм, ни хикмәт, барысы да яклау тапты.

– Бүгенге вазгыятьтә инвестицияләр җәлеп итү җиңел түгел, – дип сөйләде утырыштан соң журналистларга Татарстан Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина. – Инвесторлар эшкә үз акчаларын кертә. Шуңа күрә аларга тиешле шартлар булдыру мөһим. Бүген карап тикшерелгән 8 проектның бәясе 88,5 миллиард сум тәшкил итә. Арада иң зур проектларның берсе Тукай районында логистика комплексы төзүгә бәйле. «Нәфис Косметикс» акционерлык җәмгыятенең складлар комплексы төзү проекты да әһәмиятле.

Соңгысы уңаеннан утырыш барышында бәхәс тә чыккан. Эш шунда ки, әлеге проектны Яшел Үзән районында тормышка ашырырга тәкъдим итмәкчеләр. Рөстәм Миңнеханов исә, аны югары тизлекле М12 трассасына якынрак урнаштыру әйбәтрәк түгелме, дигән фикер белдергән. Мәсьәләне уртага салып сөйләшкәннән соң, урынын үзгәрешсез калдырырга булганнар. Инвестицион проектны 2029 елга кадәр тормышка ашырырга ниятлиләр. Инвестицияләр күләме 7,5 миллиард сум тәшкил итә.

Тиздән Иннополис янында тагын бер яңа шәһәр калкып чыгачак. Анда маркетплейслар сатучылары яшәячәк.

– Бүген электрон сәүдә зур тизлек белән үсә, – ди әлеге проектны тәкъдим итүче, иseme билгеле маркетплейс директоры Линар Хөснуллин. – Интернет-кибетләрдә сәүдә әйләнеше елына 5 триллион сум тәшкил итә. Ә алдагы 4–5 елда әлеге күрсәткеч 10 триллион сумга кадәр җитәр дип фаразлана. Бик күп акча бит бу! Иннополис узендә программистларны туплаган кебек, без маркетплейс сатучыларын бер мәйданга җыярга тәкъдим итәбез. Шунда эшләсеннәр дә, яшәсеннәр дә. Проектның беренче өлешендә сәнәгать паркы төзеләчәк. Анда интернет-сатучылар да, электрон сәүдә өчен товар җитештерүчеләр дә эшли алачак. Паркта аларга салым түләүдә дә, арендa өчен дә ташламалар каралачак. Мәйданы 10 мең квадрат метр булачак бинада әлегә 20 резидент өчен тиешле шартлар тудырылачак. Проектның беренче өлешендә инвестицияләр күләме 350 миллион сум тәшкил итә. Яңа шәһәр ни өчен нәкъ менә Югары Осланда урнашачак соң? Бу сорауга да җавап бар. Күп кенә маркетплейсларның складлары бирегә урнашкан, электрон сәүдәгәрләр шәһәре М12гә дә якын булачак.

Иң тиз тормышка ашачак проект та билгеле. «Алабуга» махсус икътисадый зонасында быел ук теләсә нинди юлдан йөри ала торган «Бурлак» машиналары җитештерә башлаячаклар.

– Инвестор безгә 20 мең квадрат метрлы бина сорап мөрәҗәгать итте. Техник яктан җитештерү өчен тиешле таләпләргә туры килүче складларны республика күләмендә барлап чыктык. «Алабуга»дан да яхшырак туры килә торганы юк. Җитештерүне башлау өчен ике яктан да бар да әзер. Документларны гына рәсмиләштереп бетерәсе калды. Инвестиция күләме – 1 миллиард 200 миллион сум, – диде Талия Миңнуллина.

Ә менә Буа балык төбәгенә әйләнеп китмәгә. Аны күпләп җитештерә башламакчылар.

– Районда балыкны тирәнтен эшкәртү эшен җайга салырга тәкъдим иттек, – ди «Унипарк» ҖЧҖ генераль директоры Марат Шакиров. – Бу эш сәнәгать паркында оештырылачак. Идарәче оешма булачак, без биредәге резидентларга көндәшлеккә сәләтле шартлар тудырырга тырышачакбыз. Балыкка килгәндә, аны биредә үрчетү дә, кумартлап тирәнтен эшкәртү дә каралган. Башка резидентларга да ишекләр ачык. Сәнәгать паркының гомуми мәйданы 28 гектар тәшкил итә. Җиде ел эчендә шуның 20 гектарга якынын файдаланырга ниятлибез.

Эштән куркыкмаган кешегә бездә мөмкинлекләр җитәрлек, кыскасы. Аларга да файда, безгә дә. Талия Миңнуллина сүзләренә караганда, әлеге проектларны тормышка ашыруның беренче чиратында гына да 1 меңнән артык яңа эш урыны барлыкка киләчәк.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Хыял өчен акча

Республикада эшләүче коммерциягә булмаган оешмалар арасында дәүләттән грант алу мөмкинлеге бирә торган бәйге башланды. Проектлар бәйгесенең приз фонды күләме үзгәрмәгән, ул быел да 35 миллион сум тәшкил итә.

Бу хакта «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат конференциясендә Татарстанның Иҗтимагый палатасы рәисе, Коммерциягә булмаган оешмаларга грант бирү республика комиссиясе рәисе Зилә Вәлиева сөйләде.

– Әлеге бәйгегә гаризалар кабул итә башладык. Ул март ахырына кадәр дәвам итәчәк. Бу инде – өстәмә бәйге. Аны булдыру тәкъдиме белән Татарстанның Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин чыкты. Без аңа бик рәхмәтлебез. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән гражданлык җәмгыятьләрен үстерү өчен матди мөмкинлек булдырыллы, – диде Зилә Вәлиева.

Әлеге бәйгедә катнашып, күп кенә оешмалар үзләренең проектларын тормышка ашыра. Мондый мөмкинлек турында бер белеп алган оешмалар, бик теләп, кабат катнаша икән.

– Үз фикерен, әйтер сүзен, эшлисе эшен булса, проектының тәкъдим итәргә кирәк. Әгәр ул яклау тапса, һичшиксез, акчалата ярдәм каралган. Шөкер, безнең бәйгедә кечкенә авылларда урнашкан коммерциягә булмаган оешмалар да катнаша. Араларында 90 мең сум акча отучы да бар. Авылда курчак театры оештыручылар бар. Шулы аз гына кебек тоелган акча аллә нинди эшләр башкарырга мөмкинлек бирә узләренә. Узган ел 230 оешма җиңүчеләр исемлегенә электе. 1 миллион сумга кадәр акчага ия булучылар бар иде, – ди Зилә Вәлиева.

Бәйгедә катнашуның үз тәртибе бар. Гаризаны дөрес тутырырга кирәк. Оешманың салым түләү буенча бурычлары булмавы да шарт. Гаризада бер генә хата җибәрү дә ярамый.

Документларны ничек дөрес тутырырга? Татарстанның икътисад министры урынбасары Олег Пелевин искәртүенчә, республикада 6 ресурс үзәге эшли. Алар нәкъ менә шушы юнәлештә катнашучыларга грант оту мөмкинлекләрен аңлата. Татарстанның Иҗтимагый палатасында грант отарга теләүчеләрне укыта да башлаганнар.

– Татарстанда 6 меңнән артык коммерциягә булмаган оешма теркәлгән. Соңгы алты ел эчендә бәйгегә тәкъдим ителгән 600 проект тормышка ашырылды, – ди Олег Пелевин. – Катнашучыларга актив булырга киңәш итәр идем. Бәйге турында мәгълүматларның барысы да безнең министрлык һәм НКО сайтында бар. Әмма грант алу өчен документларны «грантытатарстана.рф» сайтында калдырырга кирәк.

Зилә Вәлиева фикеренчә, коммерциягә булмаган оешмалар вәкилләре дәүләтнең әлегә игътибары җитмәгән проблемаларны күтәрә. «Бу оешмалар җитәкчеләр өчен авыр сорауларга бирә, булмаганны эшләтә. Әмма алар барысын да халык өчен эшли. Соңгы арада махсус хәрби операциядәгеләргә ярдәм итүче, хайваннарны яклаучы, экологияне кайгыртучы оешмалар барлыкка килде. Алар бу бәйге ярдәмендә үзләренең башлаган эшләрен ахырга җиткерә, яңаларын тормышка ашыра», – ди палата рәисе.

Бәйгегә гаризалар март ахырына кадәр кабул ителә. Нәтиҗәне июль аенда ясаячаклар.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Дәүләт Советы депутатлары игътибарына

Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының кырык икенче утырышы 23 март көнне (10.00 сәгатьтә башлана) Дәүләт Советы утырышлар залында үткәрелә.

Депутатлар Дәүләт Советы бинасында 23 мартта 8.00 сәгатьтән башлап теркәлә. Белешмәләр алу өчен телефон: 267-63-62.

Сак булыгыз!

КУРКЫНЫЧ ЯНӘШӘДӘ

Күрше төбәкләрдә хайваннар арасында төрле йогышлы авырулар чыккалавын әледән-әле хәбәр итеп торабыз. Инде менә якын күршебез Чувашиянең Цивильск районында ике кешенең себер түләмәсе (сибирская язва) йоктыруы билгеле булды. Татарстанга куркыныч янмыймы? Шул хакта белештек.

– Бездә булган мәгълүматлар буенча, авыру шәхси хуҗалыкта килеп чыккан, – дип аңлатма бирде безгә Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары Габделхак Мотыйгуллин. – Авыру чыганагы булып торган терлек шушы ук хуҗалыкта үскән, ягъни аны якын аралар да гына каяндыр алып кайтмаганнар. Ускән малны чалырга дип, ике сугымчы чакырганнар. Менә шулар авыру йоктырган да инде. Соңгы елларда Чувашиядә себер түләмәсе белән зарарланган очраклар юк иде. Бу юлы каян килеп чыккан ул? Тикшерү тәгәлләнгәнче, ниндидер нәтиҗәләр чыгару да иртә.

Табиблар авыру кешеләр белән аралашкан тагын 126 кешене дә күзәтеп тора, диелә матбугатта чыккан хәбәрләрдә.

Аңлатып узыйк: себер түләмәсе – хайваннарда һәм кешеләрдә була һәм бик тиз арада тарала торган куркыныч авыру. Ул кешеләргә мөгезле эре терлек, сарык, ат, сирәк очракларда дуңгыз һәм кәҗәләрдән йога ала. Авыру терлекләрдән алынган продуктларны куллану да инфекция чыганагы булырга мөмкин. Иң куркынычы – һавадагы тузанны сулау юлы белән зарарлану, ди белгечләр. Бу траншея казыганда, бина, корылмалар салганда булырга мөмкин.

Элеккеге елларда терлекләр себер түләмәсе белән еш һәм күп авырган. Республикада да бу авырудан үлгән маллар күмелгән үләт базлары бар. Инфекция туфракта меңәр ел яшәргә сәләтле. Шуңа күрә мондый урыннар шулай ук куркыныч тудыра. Белгечләр аеруча язгы кыр эшләре вакытында игътибарлы булырга куша.

Әлегә авыру буенча Татарстанда вазгыять имин, тик аның ни дәрәҗәдә тиз таралуын искә алсак, саклану чараларын күрү, халыкка авыру билгеләрен белеп тору бер дә зыян булмас.

Авыру билгеләренә килгәндә, зарарланган терлек бик тиз арада үлә. Авыру малның борыныннан, авызыннан канлы сыекча килергә мөмкин. Моннан тыш үлгән малның тәне катып китми дә аның себер түләмәсе белән зарарлануын күрсәтә ала. Кешеләрдә исә авыруның беренче һәм төп билгесе – тәнгә (бигрәк тә кулларга) кара төеннәр чыгу.

Россельхознадзорның Татарстан буенча идарәсенең булек җитәкчесе Идрис Гатин әйтүенчә, ике республика арасындагы постларда тикшерү көчәйтелгән. Буа һәм Югары Ослан районнары, шулай ук Чаллыдагы постларда белгечләр эшли.

– Сөт, ит, катнаш азык, терлек ташучы фураларны, җиңел машиналарны тикшерәбез. Республикага терлек күп керә. Узган елда гына 50 меңгә якын мөгезле эре терлек алып кайттылар, – диде ул.

Габделхак Мотыйгуллин да чит төбәкләрдән мал сатып алганда, ветеринария документлары булырга тиешлеген кабаттан искә төшерде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Малны бары тик рөхсәт ителгән очракта гына алып кайтырга ярый. Шулай ук теге яки бу районнан терлек алырга ярыймы-юкмы – мал табибларыннан анысын да белешергә кирәк, – диде ул.

Исегезгә төшерәбез: соңгы тапкыр әлеге куркыныч авыру 2014 елда Кукмара районының Өлге авылында килеп чыккан иде. Ул вакытта кул астында шеш барлыкка килгән, бер ир-ат табибка мөрәҗәгать итә. Авыруны исә ул сыерыннан йоктырган булып чыккан. Малны чалганнан соң бернигә көн узгач, узендә дә авыру билгеләре сизә башлый. Аңа кадәр Татарстанда себер түләмәсе 2003 елда теркәлгән. Ул вакытта Яшел Үзән районында йөздән артык кеше табиб күзәтүе астында булган. Бәхеткә, бу очракларда авыру таралмасын өчен барлык чаралар вакытында күрелде.

Зөһрә САДЫЙКОВА

СОҢГЫ МОГИКАН

КАЗАНДА ЛЕГЕНДАР ҖЫРЧЫ ЭМИЛЬ ҖӘЛӘЛЕТДИНОВ БЕЛӘН ХУШЛАШТЫЛАР

Зәвыклы, зыялы, татар җырын профессиональ югарылыкка күтәргән соңгы могикан. Танылган җырчы, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Эмиль Җәләлетдиновны якыннары, хезмәттәшләре әнә шулай дип искә ала.

«Татар-информ»

Татар халкының ни дәрәҗәдә укымышлы, зәвыклы, зыялы халык икәнен күрсәтә торган матур шәхесебез иде. Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе директоры Кадим Нуруллин хушлашу мәрасимендә шулай диде:

– Эмиль Җәләлетдинов кабатланмас шәхес иде. Мин аны татарның каһарманы дип тә атар идем. Ул җырсыз, шигырьсез беркемгә дә мөрәҗәгать итмәде бугай. Сәгатьләр буе яттан шигырь сөйли, җырлый ала иде. 2 июльдә 90 яшьлек юбилее буласы иде. Шуңа әзерләнеп йөрде. Хәер, 80 яшендәге кебек тыйнак кына баш тартырга мөмкин иде. Шундый кеше иде ул. Андыйлар башка булмас инде.

«Заманында Алмаз Монасыйповның «Тукай аһәңнәре» циклы Габдулла Тукай премиясенә лаек булды. Ул циклны тәкъдим итүче нәкъ менә Эмиль Җәләлетдинов иде. Әлбәттә, бу премияне җырчының үзенә дә бирергә кирәк булгандыр», – ди Татар дәүләт филармониясенең һәм Татарстан дәүләт фольклор музыкасы ансамбленең сәнгать җитәкчесе Айдар Фәйзрахманов:

– Эмиль абый бик итагатьле, тәртипле иде. Аның үз-үзен сәхнәдә тотышы да, җырлары да – шуңа дәлил. Эмиль абыйны студент чагымнан ук беләм, ул вакытта ук Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшли иде. Шәхес буларак та, җырчы, музыкант буларак та гел камилләште. Барлык профессиональ композиторлар үзләренең җырларын халыкка, киң тамашачыга нәкъ менә Эмиль Җәләлетдинов башкаруында ирешүен телиләр иде. Ул Алмаз Монасыйпов, Рөстәм Яхин, Нәҗип Җиһанов, Фасил Әхмәтов кебек мәшһүр композиторларыбызның җырларын башкарды. Соңгы көннәренә кадәр иҗат белән янып йөрде. Бик матур, озын гомер кичерде Эмиль абый. Шулай да, арабыздан китүе бик кызганыч. Ник дигәндә, халкыбызга чын мәгънәсендә җиң сызганып хезмәт итте, җыр мирасыбызны югары дәрәҗәгә күтәрде. Яшь җырчыларыбызга эталон булырлык, кыйбла тотарлык иҗат калдырды.

Татарстанның халык артисты Шамил Әхмәтҗанов чордашын болай дип искә алды:

– Мин әле аның Казанга килгән вакытларын, консерваториядә имтихан биргәнен дә хәтерлим. Спорт киеменнән, юка гәүдәле генә, чибәр егет иде. Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбленә эшкә килгәч, миңа аның белән бергә тулай торакта да яшәргә насыйп булды. Бер бүлмәдә Рамил Курамшин, Эмиль абый һәм мин тордык. Шулкадәр чиста, пөхтә, бик ачык күңелле, яшәү дәрте белән яши торган һәм бик төгәл шәхес иде. Җырларын әйтмим дә инде. Мин аларны башкара алмадым. Ярышып җырлаган чаклар да булды. Әле гел исәнлеген-саулыгын тикшереп яши идем, күңелсез хәбәр кичә бакчада чакта килеп иреште. Шундук Казанга җыенып чыгып киттем. Үзеннән соң тау кадәрле иҗат калдырып китте, инде ахирәт бәхетләренә ирешсен.

Үзенә бер аерым шәхес иде. Татарстанның атказанган артисты Газинур Фарукшин мәрхүмне шулай дип искә алды:

– Консерваторияне тәмамлап, филармониягә эшкә килгәч тә, Эмиль абый белән бергә эшләдек. Аның белән бик күп концертларда бергә чыгыш ясарга туры килде. Камера әсәрләрен дә, эстрада җырларын да бертигез матур итеп башкара иде Эмиль абый. Аның репертуары бик бай. Ике концертта бер үк җырны җырламагандыр да ул. Гел алыштырып тора иде, музыкантлары да аптырыйлар иде аңа. Кешелекле, тәртипле иде. Сәламәт яшәү рәвеше алып барды. Хәтта кыш көне дә, чыгып, кояш астында кызына торган гадәте бар иде.

Гомере буе үз дәрәҗәсен белеп яшәде, җырлады. Язучы Ләбиб Лерон шулай диде:

– Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова кебек үк танылган җырчыларыбызның берсе иде. Гомере буе үз дәрәҗәсен белеп яшәде. Мине иң нык сокландырган сыйфаты Тукай иҗатын өйрәнүе, аның шигырьләрен яттан белүе иде. Яттан белү, сөйләү – бер хәл, ул аларның күбесенә үзе көйләр дә язды. Шуларны очрашкан чакларда көйләп тә күрсәтер иде. Нинди генә очрашу, концерт, чара булса, ул анда бармыйча калмый иде. Җилдәй җитез иде. Мине иң гаҗәпләндергәне: көн саен баштүбән торам дип әйтә иде. Шушындый бер эпоха, легенда булырлык шәхесләребезнең арадан китүе күңелгә авыр, әлбәттә. Аларның җырлары мирас булып, халкыбызның алтын фондына кереп калды. Менә бүген дә озату вакытында аның җырлары яңгырый. Алар күңелнең нечкә кылларына тиеп, тибрәтеп ала.

Монысы – Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Равил Шәрәфиев хатирәләре:

– Узган елны гына Татарстан урамы буйлап велосипедка утырып, янымнан узып китте. Сокландым. Мин үзем дә велосипедта йөрергә яратам, ләкин инде хәзер утырырга куркыр идем. Дөрес яшәмәсә, бу яшькә җитә алмас иде. Җаны да, тәне дә сәламәт иде. Бөтен нәрсә белән кызыксынды. Шигырен дә укыды, җырын да җырлады. Минем тагын бер яраткан җырчым Рафаэль Сәхәбиев укырга килгәндә: «Минем кумирым – Эмиль Җәләлетдинов, мин шул планда җырларга җыенам», – дигән иде. Бу – бик зур әйбер. Бик якты, тырыш, булдыклы, талантлы кеше иде. Урыны җәннәттә булсын.

Ләйсән САФИНА

МАТЕМАТИКА УКЫТУЧЫСЫ КАМИЛ АБДУЛВАХОБОВ:

«ҺӘР ИРТӘДӘ ТАТАРЧА 2–3 ХӘБӘР УКЫЙМ»

2023 – Укытучы һәм остаз елы

Начар укучыдан «отличник» ясап буламы? Зәңгәр чәч өчен кисәтү ясаргамы? Ни өчен ир укытучылар мәктәпкә килми? Казанның 187 нче лицее математика укытучысы, Казан шәһәренең «Ел укытучысы – 2022» бәйгесенең «Педагогик дебют» номинациясе җиңүчесе Камил АБДУЛВАХОБОВ белән бүгенге мәктәп, яшь укытучыларны җәлеп итү, һөнәрне ярату турында сөйләштек.

:: Камил Рөстәмович, сезгә, инженерлык белеме алган белгечкә, «Мәктәптә нишләп йөрисез?» дигән сорауны еш бирәләрдер. Чынлап та, ни өчен нәкъ менә укытучылыкны сайларга булдыгыз?

– Мәктәпне алтын медальгә тәмамлап, Казан илкүләм тикшеренүләр техник университетында (КАИ) «электроникада нанотехнологияләр» юнәлешендә белем алдым. Яшермим: әлеге белгечлек миңа «запас аэродром» кебек иде. Әгәр укытучының хезмәт хакы гаиләне туендырырга җитмәсә, инженер булып эшли алам бит. Башта аена 30 мең сум түләсәләр, берничә айдан тагын артачак. Үзем укыган вуз кафедрасында тикшеренүләр алып барырга да тәкъдим иттеләр. Диссертация язып, рейтингы зур булган журналларда бастырып, Европа илләренә китеп, яхшы хезмәт хакы алырга була. Әмма минем Татарстанга файда китерәсем килде. Аны ташлап китү минем өчен хыянәт булыр иде.

Техник вузда укыганда, укытучы булачагымны аңлаган идем инде. Ни өчен дигәндә, күңелдә балаларга белем бирү теләге бар иде. Шуңа күрә 4 нче курста математика һәм физика укытучысына һөнәри әзерлек үттем. Студент вакытта ук мәктәптә математика укыта башладым. Өченче ел укытам. Кайда эшләвемне белгәч, танышларым гаҗәпләнә. «Ничек инде дәрәҗәле техник вузда яхшы инженерлык белеме алып, гади математика укытучысы булып эшләргә мөмкин? Син, чыннан да, тормышыңны мәктәпкә багышларга җыенасыңмы?» – дип тә аптырап сорыйлар. Кем өчендер тормыш мәгънәсе – югары хезмәт хакы, җәмгыятьтә дәрәҗәле урын, кемгәдер – нык гаилә яки үзеңне гыйльми һәм рухи яктан үстерү. Минем укучылар күңелендә якты эз калдырасым килә. Әнием балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Кечкенәдән аның сабыйларны яратуын, сабырлыгын күреп үстем. Гаиләдә берәү дә миңа укытучы булу фикерен такмады. Әмма әни, сиздермичә генә, күңелемә педагогиканың беренче орлыкларын салды. Казанның Нагорный бистәсендәге гап-гади 124 нче мәктәптә белем алдым мин. 9 нчы сыйныфта укыганда, тәрбия эшләре буенча урынбасар укытучылыкка кызыксыну уятты. Фәннәр патшасын исә математика укытучым яраттырды.

:: Замана укучылары белән эшләү җиңел түгелдер. Яшь укытучыны санлыйлармы соң?

– Миңа – 23 яшь. Үзем дә шул балалардан ерак китмәдем бит әле. Яшь булгач, алар белән уртак тел табу авыр түгел. Вузны тәмамлагач, башкаладагы 49 нчы мәктәптә укыта башладым. 10–11 нче сыйныфларда физика дәресләре алып бардым. Яшь аермасы – нибары 3–4 ел гына. Дәрестә мин укытучы булып калам. Төп бурычым – баланы олы тормышка әзерләү. Сыйныфларда балалар саны 30–35кә җитә. Һәрберсенең күңеленә ачкыч табарга кирәк. Дәрес кызык булырга тиеш. Югыйсә белемне җиткереп булмаячак. Аларны ишетергә, нәрсә теләгәннәрен аңларга тырышам. Әти-әниләр белән дә дуслык кирәк. Өч як: укытучы, укучы, әти-әни дөрес эшләгәндә генә уңышка ирешергә мөмкин.

:: Математикага бөтен укучының теше үтми. Гуманитар профильле сыйныфлар да бар бит. Ничек уйлыйсыз, «икеле-өчле»гә укучыдан отличник ясап буламы?

– 187 нче лицейга быелгы уку елында килдем. Анда төрле профильләр эшли. Шул исәптән, гуманитар да. Миңа 8 нче гуманитар сыйныфны бирделәр. Балаларның күбесе телләр белән кызыксына. Шуңа күрә һәрберсенә аерым якын киләм. Дәресләремне тормышка бәйләп аңлатам. Бу – кызыксыну уятуның бер төре генә. Педагогик технологияләр күп бит. Күп нәрсә укытучы теләгеннән тора. Начар укучыдан да отличник ясап була. Бары аның мөмкинлеген һәм тырышып укымавының сәбәбен белергә генә кирәк.

:: Репетиторлыкка ничек карыйсыз? Үзегез дә шөгыльләнәсезме?

– Бүген укытучыларның күбесе шөгыльләнә. Кызганыч, хезмәт хакы педагогларга уңайлы, рәхәт тормыш алып бару мөмкинлеге бирми. Репетиторлыкка начар карамыйм. Чынбарлыкта ул балада аерым фәнгә кызыксыну уяту мөмкинлеге бирә. Кайчак мәктәптә баланы аңлау да җитми. Шулай итеп, белем алу теләге сүнә.

Мин әле өйләнмәгән, ипотекам да юк. Акча җитә, укытудан тыш, директор урынбасары вазыйфасын да башкарам. Репетитор булуга ихтыяҗ юк, диюем. Үз һөнәремдә иң яхшысы буласым килә.

:: Чәчләрен аллы-гөлле төсләргә буяп, ертык джинсы киеп, дәрескә килгән укучыларга кисәтү ясыйсызмы?

– Үзем чәчләрне яшел, шәмәхә төскә буяп йөрүне хупламыйм. Тәрбиям башка. Кайбер укучылар шул рәвешле үзләренә игътибар җәлеп итәргә тели. Ачуланганым юк. Болай йөрү бик матур күренеш түгел, дип җайлап кына аңлатам. Алай әйткәндә, колакларына керә.

:: Дәресләрдә укытучыны фото, видеога төшерүне тыярга җыеналар. Балаларның телефон белән мавыгуы сезне дә борчыйдыр...

– Укытучылар болай да кысада яши. Әйтик, социаль челтәрләрдә шәхси тормышны, ялларны күрсәтә алмыйбыз. Әхлак, шәхси үрнәк дигән нәрсә бар. Әти-әниләр барысын да күзәтеп тора. Су коену урынында фотога төшеп, интернетка куйсалар, җәмгыятьтә бик тиз ризасызлык уяна. Дәресне камерага төшерсәләр, ирекне тагын да чикләү булачак. Телефонда утыру – бәла. Укучылар буш вакытын интернетта уздырмасын өчен, коридорларда өстәл уеннары булырга тиеш. Бездә шулай. Спорт залы янәшәсендә кул көрәштерү буенча җиһазлар куелган. Шартлар тудырганда гына, без телефонда утыруга каршы көрәшә алабыз. Әгәр телефонга – «юк» дибез икән, без алмашка нәрсә тәкъдим итә алабыз? Элек китап укысалар, хәзер укучылар классик әдәбият, зур романнар белән кызыксынмый. Балаларда – «клип күзаллавы». Аларга мәгълүмат кыска һәм кызык булсын.

:: Быел Укытучы һәм остаз елынданиләр көтәсез? Ир укытучыларны мәктәпкә ничек җәлеп итәргә?

– Укытучының абруен күтәрүне. Минем кебек яшьләр мәктәптә күп булсын өчен, хезмәт хакын арттыру кирәк. Яшь укытучыга ярдәм итәргә остаз билгеләнсен инде. Ни өчен дигәндә, баштагы мәлдә күп нәрсә аңлашылып бетми. Укытучы һөнәренә игътибар бирә башладылар, Аллага шөкер. Бу – әлеге һөнәрнең җәмгыятьтә социаль әһәмиятен аңлау дигән сүз.

Ир укытучылар җитми, матриархат заманы. Балаларга ир кулы, роле кирәк. Иң яхшысы – укытучы һөнәренә кызыксынуны мәктәптән үк башлау. Мин лицейда психолог-педагогик сыйныфны җитәклим. Профильле укыту укучыда укытучы һөнәренә карата ялкын кабызырга булыша.

:: Казанда тусагыз да, татарча яхшы беләсез. Бу гаиләдән киләме?

– Гаиләдә әти-әниләрем рус телендә аралаша. Татар телен камил белмим, әмма өйрәнәм. Һәр татар туган телен, тарихын, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен белергә тиеш дип саныйм. 9 нчы сыйныфтан соң «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең кичке бүлегенә укырга кердем. Анда дәресләр татар, гарәп телләрендә иде. Кыскасы, шул дүрт елның туган телемне өйрәнүдә файдасы зур булды. Дус кызларым: «Син һәр иртә 5–10 минут булса да татарча китаплар укы», – дип киңәш итте. «Ватаным Татарстан» газетасының «ВКонтакте» төркеменә язылдым әле. Иртән эшкә киткәнче, 2–3 хәбәр булса да укырга гадәтләндем. Укытучылар турында язуыгыз өчен рәхмәт, безнең һөнәрне, аның дәрәҗәсен күтәрәсез.

Сәрия МИФТАХОВА

Әйтеп кенә бактым

Цензура

Миннән еш кына: «Сезнең газетада цензура көчлеме?» – дип сорыйлар. Бу сорауга бер җөмлә белән кыска гына җавап биреп тә, «әйе» яки «юк» дип кистереп әйтеп тә булмый. Ык-мык итеп торсам: «Дөресен язарга куркасыз!» – дип батырая да башлыйлар.

Халыкта «Авызың ни әйткәнне колагың ишетсен» дигән әйтем бар. Мәгънәсе белән бу әйтем үзе үк цензурага тартым, ягъни «телеңә ни килде шуны сөйләп йөрмә» була инде.

Әле XVIII гасырда яшәгән классик фәйләсуфлар Иммануил Кант белән Георг Гегель дә цензура мәсьәләсендә капма-каршы фикердә торганнар. Беренчесе сүз ирекен алга сөрсә һәм, һәркемнең үз фикерен әйтергә хакы бар, дисә, икенчесе, сүз ирекe законнар белән көйләнергә тиеш, дигән. Ике фикер, гасырлар узып, хәзерге көнгә хәтле яши, «цензура» дигән сүзгә һәркем үзенчә мәгънә салырга тырыша. Ул – латин сүзе, безнеңчә «кырыс тәнкыйть» дигәнне аңлата. Әлбәттә, тәнкыйть беркайчан да «кәнфит» булмаган инде ул. Һәр чорның үз цензурасы, ягъни чикләүләре булган. Цензура, гадәттә, җәмгыятьтә тотрыклылык, иминлек саклау максаты белән кертелә.

Сүз ирекe төрле илләрнең Конституцияләрендә язылган үзе, әмма шул ук вакытта, Төп Законда кеше фикеренә колак сала белү кирәклеге дә, җәмгыятьтә каршылыклар, тетрәнүләр китереп чыгарырга омтылу өчен җинаять җаваплылыгы турында да язылган. Кайчандыр бөек юлбашчыбыз саналган Ленинчарак әйтсәк, «җәмгыятьтә яшәп, аңа бәйсез булу мөмкин түгел», ягъни син кабул ителгән законнар, яшәү рәвеше, традицияләр кысаларында яшәргә тиеш буласың.

Үзем язам, үзем «акыл сатам» кебек тоела. Мин «Ленин башлы» түгел, материалист Иммануил Кант, идеалист Гегель кебек тә була алмаячакмын. Әйдәгез, гади генә телгә күчеп сөйләшик. «Өйдәге чүпне тышка чыгару» дигәнне ишеткәнегез бардыр, бу сүзләрне үзегез дә еш кулланасыздыр. Бәлки, кайчак телегезне аркылы тешләргә дә туры киләдер. Чөнки ярамый икәнен чамалыйсыздыр. Цензура – әнә шул инде ул. Сөйгәнегез яки якын кешегез белән үзегез генә белергә тиешле серләрне дә чат саен сөйләп йөрмисездер. Чөнки бөтен халык белсә, арагыз бозыласын сизәсез.

Яшерен-батырын түгел, кайчак без «сүз ирекe»н, ни сөйләсәм дә ярый, авызымны капларга берәүнең дә хакы юк, дип кабул итәбез. Мондый «сүз ирекe» еш кына провокациягә тартым була, ягъни без тормышка ашмастай сүзләр сөйләп, батыр булып кыланып, үзебез өчен өстәмә мәшәкатьләр тудырабыз. Теге яки бу мәсьәләдә гаеплене эзләп, үзебезгә дошман табабыз, хакимиятне сүгәбез, дусларыбыз белән талашып бетәбез. «Провокация» – латин сүзе, урысча «вызов» дигәнне аңлата, безнеңчә чакыру, чакыру ташлау була инде. Моннан кемгә файда?

Соңгы вакытларда милләт, тел язмышына бәйле бәхәсләр куерды. Хәер, моны «бәхәс» дип әйтү бик үк дөрес түгел, чөнки бер бакчага гына таш ату бара. Татарны, телебезне бетерүдә югары түрәләрне, аерым бер милләтне гаеплибез. Дәшми торучыларга «куркак» дигән тамга салабыз, аларны төрлечә мыскыл итәбез. Әмма милләтне бөек, абруйлы итү юлларын күрсәтү нигәдер башыбызга килми.

Сабакташым, халык шагыйре Зиннур Мансуровның әйткәннәре искә төште әле. Университеттан соң ул, армиягә алынып, Еврей автономияле өлкәсендә, Биробиджан шәһәрендә хезмәт иткән иде. «Яһүдләр үз баласын кечкенәдән үк зур кеше булырсың дип үстерә, укыта, тәрбияли. Милләтне алар эш күрсәтеп саклый», – дигән иде Зиннур. Яһүдләр үзләренең инде тәмам юкка чыккан телләрен яңадан тудырдылар. Иң әһәмиятлесе: «Телебезне кисәләр, милләтне бетерәләр!» – дип каравыл кычкырмадылар, үзара талашмадылар.

Яһүдләр бүген бөтен дөньяны тота диярлек. Ә татар? Милләт турында уйлаганда шәхсән үзем горурлык хисләре кичерәм. Россия Хөкүмәтендә татарларның шактый булуы белән дә горурланам. Җыр-музыка сәнгатендә татар тавышы яңгыравына сөенәм, илдә Татарстанның абруе зур булуына куанам. Әгәр дә дөреслекне язарга курыкмыйча, һәркемне, һәрнәрсәне уңга-сулга тәнкыйтьли башласам, телне, милләтне бетерәләр, дип адым саен оран салсам, моннан татарга нинди файда булыр икән соң?

Бер акыл иясе гади генә итеп: «Бетәм дисәң, бетәсең», – дип әйткән бит әле. Аның әйткәненә «яшим дисәң, яшисең» дип тә өстисе килә. Һәр татар үз урынында сокланырлык гамәлләр кылса, милләтне дөньяга таныта ала, башкаларны үзе белән санлашырга мәҗбүр итә дип уйлыйм. Россия Президенты Владимир Путин гына түгел, башкалар да, бүтән халыклар да: «Куда нам без татар!» – дип әйтерлек булсын иде ул. Болай яшәр өчен бернинди цензура да киртә була алмый. Бер-беребезнең кадерен белик, «Татар бер-берсен ашар» дигән сүзләр алдагы буыннарга да күчмәсен иде.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың төзелеш тармагын үстерүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Связьинвестнефтехим» акционер җәмгыяте генераль директорының төзелеш секторы мәсьәләләре буенча урынбасары **Абдуллин** Тәлгать Мидхәт улы; татар милли мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә мөһим өлеш кертүе, актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Свердловск өлкәсе (Урал татарлары) татар конгрессы» төбәк иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Бикбов** Равил Зөфәр улы; республикада җәмәгать туклануы системасын үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Мәктәптә туклану комбинаты» акционер җәмгыяте генераль директоры (Азнакай шәһәре) **Гафиятуллин** Мансур Арслангали улы; республиканың ягулык-энергетика комплексын үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Челтәр компаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры урынбасары – икътисадый сак һәм режим буенча директоры **Кашапов** Алмаз Вахит улы; прокуратура органнарында күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Ломакина** Надежда Константиновна; республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстанның агробизнес кадрларын яңадан әзерләү институты» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры вазыйфаларын вакытлыча башкаручы, агросәнәгать комплексын механикалаштыру һәм цифрлы нигезгә күчерү кафедрасы мөдире **Титов** Николай Леонидович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Шәңгәлче авыл җирлеге башлыгы **Сәлимов** Рамил Хәсән улы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен Татарстан Республикасы прокуратура органнары ветераны **Галимов** Газинур Сабирҗан улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты» муниципаль казна учреждениесе рәисе урынбасары **Гарипова** Римма Булат кызына **«Татарстан Республикасының атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«БӨРЕЛЕ» ябык акционер җәмгыятенең төзелеш һәм монтажлау эшләре мастеры (Татарстан Республикасының Биектау районы) **Вафин** Фаяз Хәнәфи улына, «Казан ДСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең проект документлары белән эшләү буенча әйдәүче инженер-технологы **Маклеева** Наталия Петровнага **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

Әйләнә дә килә... кунаклар

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Экскурсовод хезмәтенә бәя үсүенә дә аптырарга кирәк түгел дип саный Раушания ханым. Ул һәрвакыт белем алу, үзен үстерү юлында бит. Китаплар укыйм, курсларга йөрим дисәң дә, акча кирәк. «Дәүләт аккредитациясе» дигән төшенчә дә бар. Аңа әзерлек тә матди һәм рухи мөмкинлекләр, хезмәт таләп итә. Гильдиядә исәптә торсаң, взнос та түлисе. Экскурсоводларның акчасын санаганда, Раушания ханым әнә шуларны да исәпкә алырга кирәк дип уйлый.

– Хәзер бәя бөтен җирдә дә уйный бит. Экскурсоводлар гына читтә калмас, – ди Раушания ханым, уенын-чынын бергә кушып.

Тиздән язгы каникул чоры җитәсен исәпкә алып, тәҗрибәле экскурсоводтан балалары булган гаиләләргә кызыклы маршрутлар сораштык.

– Зөя, Болгар, Алабуга, Кырлай – болар инде популяр урыннар. Төрледән-төрле остаханә, квест, программалар уйлап табып кына торалар бит. Менә шуларда катнашу гаиләләргә кызыклы булыр иде дип уйлыйм. Алар берләштерә. Сер түгел, хәзер балаларыбыз белән сөйләшеп утырырга әллә ни вакыт тапмыйбыз да бит. Әйтик, рәсем, балчыктан нидер ясау кебек мастер-класслар вакытында берәү дә телефонга игътибар итми, тулысынча эшкә бирелә, аралар якыная, – диде ул. – Кама аръягы еш кына игътибарыбыздан читтә кала. Шөгердәге нефть музеена барырга кирәк. Ул – шулкадәр мавыктыргыч урын. Әлмәттә уен кораллары музее эшли. Уйнап карарга да рөхсәт итәләр.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы ветераннар советы президиумы, шәхсән Совет рәисе М.Ш. Алиев, заманында Чүпрәледә район Советы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасында булган, район үсешенә ифрат зур өлеш керткән шәхес, талантлы оештыручы, Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре

Илшат Хәйрулла улы ЮСУПОВ

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең туганнарының, якыннарының, фикердәшләренең авыр кайгысын уртаклаша.

Спорт

Кертә алмадылар

Тигез итеп бүлделәр. Чаллыда «КАМАЗ» белән «Рубин» арасында узган очрашу 0:0 исәбенә тәмамланды. Бу очрашуны күптән көтсәләр дә, тамашачы гол керткәнне күреп ләззәтләнә алмады.

«КАМАЗ» белән «Рубин»ның Чаллыда инде 25 ел уйнаганы булмаган икән. Ул вакыт эчендә ике команда тарихында күп вакыйгалар, зур борылышлар булды. Берсе игътибар җитмәүдән интексә, икенчесе туп һәм миллион долларлар белән уйнады. Нәтиҗәдә «КАМАЗ»ның яшәү белән үлем арасында калганын да күрдек. «Рубин» исә, киресенчә, өскә күтәрелеп, Россия Чемпионатын һәм Кубогын отты, Чемпионнар Лигасында чыгыш ясады. Ә узган ел тигезләштеләр: икесе дә беренче лигада очрашты. Чаллы командасы баштарак беренче урында барды, Казан уенчыларына лидерлар арасына керү җиңел бирелмәде.

Чаллыда бу матчны нык көттеләр. Уен кыры мактарлык хәлдә булмагач, «КАМАЗ» футболчылары, әзерләнү өчен, хәтта Түбән Камага барып йөрде. «Волга»га каршы узган очрашуны да 40 чакрым ераклыктагы күрше калада уздырдылар. Барысы да «Рубин»ны Чаллыда кабул итү өчен. Җирле футбол сөючеләр дә әзерләнде, Казаннан да тамашачы күп килде. Җитәкчеләр дә игътибарсыз калдырмады. Матч башланыр алдыннан Салават Фәтхетдинов «Мин яратам сине, Татарстан»ны җырлады. Тупка да беренче булып җырчы белән «КАМАЗ-Мастер» узышчысы Дмитрий Сотников типте.

Тик тамашачыга гол күрергә генә насыйп булмаган икән. «Ике команда да уйнарга тырышты. Әмма мондый уен кырында нидер күрсәтү бик кыен», – диде очрашудан соң Казан командасының баш тренеры Юрий Уткульбаев. Аның фикерен уенчылар да җөпләде. Тамашачыга рәхмәт әйттеләр, уен кыры турында сөйләшмәскә тырыштылар.

Сүз уңаеннан, баш тренер вазыйфасына Юрий Уткульбаев билгеләнгәч, «Рубин» барлык очрашуларны да җиңү белән тәмамлый алды. Чаллыда аның уенчылары 1 генә очко белән канәгатьләнде. Ничек кенә булмасын, Казан командасы турнир таблицасында икенче урында бара. Якташларыбыз иң өстәге «Балтика»дан 4 очкога калыша. «КАМАЗ» – уртада. Әмма Татарстан командалары үз араларында «Өчпочмак кубогы» өчен дә көрәшә әле. Чаллыдагы очрашуда җиңгән булса, бу ярышта «Рубин» җиңәсе иде. Хәзер исә «КАМАЗ»ның мөмкинлеге күбрәк. Моның өчен аларга «Нефтехимик»ны отарга кирәк.

	Команда	уен	очко
1	Балтика	23	48
2	Рубин	23	44
3	Енисей	23	41
4	Алания	23	40
5	Волгарь	23	34
6	Динамо Мх	23	33
7	Арсенал	23	33
8	СКА-Хабаровск	23	33
9	КАМАЗ	23	33
10	Шинник	23	32
11	Родина	23	31
12	Нефтехимик	23	29
13	Акрон	23	27
14	Велес	23	23
15	Кубань	23	23
16	Уфа	23	21
17	Волга Ул	23	19
18	Краснодар-2	23	14

rubin-kazan.ru

РӘХМӘТЛЕ БӘЙГЕ

Каләм хакы

Бер генә бала да бүләксез калмады. Узган җомгада Мамадыш районының Түбән Яке авылы мәдәният йортында хезмәттәшебез Гөлгенә Шиһапова әтисе Мансур Шиһапов истәлегенә оештырган яшь иҗатчылар бәйгесенең бүләкләү тантанасы узды.

Автор фотосы

– Әлеге бәйгене туган авылымда уздыруның сәбәбе – авылдашларны бергә җыясым килү. Бу чара – бәйгегә йомгак ясау гына түгел, истәлекләр барлау да. Әлеге эшебез белән без яшь буынга үрнәк күрсәтәбез, – ди хезмәттәшебез. – Быел берәүне дә бүләксез калдырмадык. Дүрт юллы шигырь язган баланы да үсендерергә кирәк. Телефон, интернет заманында кулына каләм тоттырып, бәйгегә эшләр яздыра алганбыз икән, бу инде – үзе җиңү.

Быел унынчы мәртәбә узган республикакүләм бәйгегә барлыгы 50ләп иҗади эш килгән. Катнашучыларның географиясе киң – Татарстанның төрле районнары белән беррәттән, күрше Башкортстаннан да яшь каләмчеләрнең иҗат җимешләрен кабул итеп алганнар. Эшләрне исә, елдагыча, төп оештыручы белән бергә КФУның милли һәм глобаль медиа чаралары кафедрасы мөдире Васил Гарифуллин һәм шушы ук кафедра доценты, журналист Рәсимә Галиева бәяләгән. Васил Гарифуллин бүләкләү тантанасында да катнашты.

– Бу бәйгенең киләчәге матур булсын иде! Аның нәкъ менә Гөлгенә туган авылда узуы аеруча күңелле һәм кадерле. Шулкадәр ихлас, рәхәт бәйрәм бу. Бәйгедә катнашкан һәр балага уңышлар телим. Иҗатыгыз белән безне сөендереп торыгыз! – диде ул, җиңүчеләрне котлап.

Әйткәнебезчә, әлеге бәйгене Гөлгенә Шиһапова 39 яшендә фаҗигале төстә вафат булган әтисе – кыска гына гомерен балалар укытуга багышлаган Мансур Шиһапов истәлегенә уздыра.

– Әтиемнең әллә нинди зур исемнәре булмады. Ул гап-гади укытучы булып хезмәт итте. Гомере булган булса, зур уңышларга ирешер иде дә... Тик мин гади укытучыны хөрмәтләү яклы. Дәрәҗәле кешене болай да зурлыйлар аны, – ди хезмәттәшебез.

Әнә шул максаттан һәм 2023 елның Россиядә Укытучы һәм остаз елы булуын исәпкә алып, бәйге уздырыла башлаганнан бирле күп укучылар әзерләгән һәм, гомумән, һөнәренә фидакарьләрчә хезмәт иткән укытучыларга – биш якташына Татарстанның мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин карары белән бирелгән «Мактаулы остаз» мактау билгесен тапшырды ул.

– Укытучы хезмәтенең никадәр авыр икәнен беләм мин. Укытып кайткач, әтиемнең хуҗалык эшенә ашыгуы, аннан соң төн буе стена газеталары чыгаруы, дәрескә план язуы хәтердә. Ул вакытта, чынлап та, укытучыга хөрмәт зур иде. Ә хәзер бар да башкача. Укытучы укучы һәм аның әти-әнисеннән куркып тора. Шуларны уйлыйм да, укытучыларга үзләре исән чакта һәйкәл куяр идем, дим. Быел бу чарага 10 ел тулу уңаеннан, бәйгегә өлеше кергән, күп еллар безгә белем биргән, зур эшләре булып та читтә калган остазларга игътибар итәсебез килде. Бик рәхмәтлебез. Алар булмаса, мондый зур бәйрәм ясап булмас иде, – ди Гөлгенә Шиһапова.

Мондый дәрәҗәле бүләк алганнан соң, укытучылар әле озак кына шатлыклы күз яшьләрен тыя алмады. Мамадыш районы Җәнлек совхозы мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы, 39 ел гомерен балалар укытуга багышлаган Гөлнур Әлмиева әле дә шул хисләрдән арына алмый икән.

– Мондый бәйгеләр дәвамлы булсын! Үзем чыгышым белән Түбән Яке авылыннан булгач, бик тә тирән кичерешләр, дулкынлану, онытылмаслык хисләр белән кайттым. Чара бер сулышта үтте. Һәр баланы, укытучыны зурлау, хезмәте кергән барлык кешеләрне олылау, халкыбызны бер йодрыкка туплау, берләштерү кебек матур сыйфатлар күзгә бәрелеп торды. Укучыларның сәхнәдәге искиткеч чыгышлары, иҗади эшләр, каләм тибрәтүчеләрнең язмалары... Бигрәк тә шушы бәйгене оештыручыга – «Ватаным Татарстан» газетасы журналисты Гөлгенә Мансур кызына рәхмәтләремне белдерәм, – диде Гөлнур ханым.

Сүз уңаеннан, аның укучысы Әмир Фәрхуллин бәйгедә гран-прига ия булды. Әмир хәзерге вакытта 10 нчы сыйныфта белем ала. Киләчәктә үзен журналистика өлкәсендә күрә. Журналист булырга хыялланучы егетләр – бик сирәк күренеш хәзер. Кем белә бит, бәлки, Әмир хезмәттәшебез дә булып куяр әле.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Туган ил буйлап

ЫБ – САМОДИЛАР ИЛЕ

Автор фотосы

Әгәр кыска гына вакыт эчендә, мәсәлән, язгы каникулда теге яки бу милләтнең тарихы һәм мәдәнияте белән танышырга теләсәгез, мин сезгә этнографик паркларга барып кайтырга киңәш итәм. Сүз уңаеннан шуны да әйтеп китәргә кирәк: кайбер музейларда, паркларда өлешчә чалымнары булса да, Татарстан бу яктан өлгерлек күрсәтә алмый әле. Югыйсә туристларны җәлеп итәр өчен менә дигән урын булыр иде ул. Ә безнең иксез-чиксез Россия киңлекләрендә андый парклар дистәләрчә. Яңа ел ялын бушка уздырмас өчен, без дә шуларның берсенә – Коми Республикасындагы фин-угор паркына барып кайткан идек.

Сыктывди районында

Тугандаш 24 фин-угор һәм самоди халыкларының мәдәни тормышына багышланган турист-сәяхәтчеләр комплексы Сыктывди районының Ыб бистәсендә урнашкан.

> Ул безгә шунысы белән кызыклы: үз милли республикаларыннан тыш, фин-угор халыклары безнең Татарстанда да, укмашып-укмашып, Тәтеш, Кама Тамагы, Әгерҗе, Кама аръягы районнарында яшиләр.

Ыб үзе – 13 авылны эченә алган иң борынгы торак пунктларның берсе. Аның тарихы XIV гасырда коми-зыряннарга православие дине аша мәгърифәт алып килгән епископ Стефан Пермский исеменә бәйле. Паркта Уралның көньяк-көнчыгыш өлешенә хас гигант агачлар – әйләнәсе 2,7 метрлы карагачлар, 450 яшьлек чыршылар очрый. Анда шулай ук миллион еллар элек, юра чорында яшәгән динозавр һәм IV–V гасырларга караган алачык – Чудь шәһәрчеге, данлыклы изге чишмәләр белән танышырга була.

САН

Бүген фин-угор телләре төркемендә 24 халык исәпләнеп, шуларның 17се Россиядә дә яши.

Биләмәләре бик зур паркка туристларны җәлеп итү өчен, кунакханә дә төзеп куйганнар. Ял итүчеләргә көн саен дистәләгән танып-белү, күңел ачу программалары да тәкъдим ителә. Күбесе шушы төбәк халыкларының борынгыдан килгән һөнәрләренә бәйле. Чыпта курчак ясау, бәрәңге шаңгәсе, баллы прәннек пешерү буенча мастер-классларда катнашу мөмкинлеге туристларда зур кызыксыну уята. Яңа ел бәйрәмнәренә эләксәң, әлбәттә инде, балалар коми «салкын бабае» Кӧдзыд Пӧль белән очраша, чыршы төбендә бергәләшеп күңел ачалар. Ир-егетләргә ук, арбалеттан ату, мишеньга сөңге яки балта тидерү кебек уеннар ошый.

Кемнәр алар фин-угорлар?

Фин-угорларның кайбер төрләре Россиядә кимеп баруга карамастан, алар Европада хәзергә кадәр иң зур этник төркемнәрдән санала. Бер исемнәре мадьяр, икенче исемнәре hungary булган венгрлар, эстоннар, финнардан тыш, үзебезнең мари, мордва, удмуртларны гына искә төшерик.

Галимнәр аларның тарихи ватаннары дип Урал итәкләрен һәм Идел-Чулман бассейнын күрсәтәләр. Башта алар күчмә халыкларның эзәрлекләвеннән урманнарга качканнар. Ә биредә аларны төньяк славян кабиләләре эзләп тапкан һәм ясак түләргә мәҗбүр иткәннәр дип исәпләнә. Менә шул вакыттан көчле ассимиляцияләшү башланган да инде.

Борынгы фин-угорлар рус елъязмаларында беренче тапкыр җир эшкәртү, балык тоту, ау белән шөгыльләнүче халык буларак искә алына. Шулай ук аларның элегрәк Болгар дәүләтенә ясак түләп торуы да билгеле.

Хәзерге белгечләр, тел үзенчәлекләреннән чыгып, фин-угорларны биш төркемгә бүлеп карыйлар. Болар: Кола ярымутравы, Мурманск тирәсендә яшәүче саам төркеме, Пермь (удмуртлар, комилар, басурманнар), Балтыйк буе-фин (эстоннар, финнар, кареллар, квеннар), Идел буе-фин (мордва, мари), угор (хант, манси, венгрлар) төркемнәре. Шулай итеп безнең күршеләребез мари, мордва, удмуртлар шундый зур тел төркеме вәкилләре булып торалар.

Чудь мае

Безнең гаилә өчен сәяхәтләр – күңел ачу гына түгел. Без барган җирнең тарихын, үзенчәлекләрен өйрәнергә тырышабыз. Коми Республикасында милләттәшләребезнең саны дүртенче урында тору да безнең өчен ачыш булды. Сыктывкарның үзеннән бигрәк, алар төньякта – нефть һәм газ чыгарыла торган төбәкләрнең Воркута, Ухта, Усинск, Печора, Вуктыл кебек шәһәрләрендә яшиләр һәм эшлиләр.

Бу төбәктә нефтькә зур игътибар бирелә. Двина елъязмаларыннан борынгы заманнарда бу якларда саам һәм чудь (фин-угорларның җыелма исеме) халыкларының елга өстендәге майны җыеп, җәрәхәтләрне төзәтү өчен файдаланганнары турында билгеле. Билгеле, ул чакта моның җир астындагы зур хәзинә билгесе булуына төшенү булмагандыр. Инде күпкә соңрак бу җирләрдә нефть сәнәгате эшли башлый.

Хәзерге көндә Этнопаркта «Экомузей» биләмәләрендә «Чудь мае» дип аталган нефть сәнәгате экспозициясе эшләп килә. Музейда безне шаккатырганы рәссам Виталий Касаткинның җир мае, газ катнашмасы һәм аларның калдыкларыннан ясалган картиналары булды. Рәссамның остаханәсендә нефтьның аксыл сарыдан алып чем-карага кадәр 64 төре тупланган. Төс нинди чыганактан алынуына бәйле. Сүз уңаеннан әйтик, Татарстанда хәзер алына торганы кара-көрән төстә.

Кышкы каникулда Сыктывкардагы салкынлыкның 40 градус тирәсе булуы беркемне дә куркытмады. Балалар рәхәтләнеп ял иттеләр, кул эшләре белән шөгыльләнделәр, көннәр буе саф һавада йөрделәр. Анда ничектер һава торышы да бик үзенчәлекле: әче җилләре дә, суыклары да үзәккә үтә торган түгел. Ә без, өлкәнрәкләр, үзебез өчен мәңге истә калырлык тарихи ачышлар ясадык.

Гүзәл ӘХМӘТҖАНОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5332 данә
Гомуми тираж – 15281 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 239

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+